**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ПЕТРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**XXXXVI СЕССИЯ**

**КАРАР № 6**

Петровка авылы «20» май 2019 ел

**Бөгелмә муниципаль районы**
**Петровка авыл җирлеге Советының**
**2019 елның 14 февралендәге**
**XXXXV сессиясенең «Петровка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегендә даими нигездә**
**муниципаль вазыйфада булучыга, яше җитеп,**
**пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә,**
**бер тапкыр акчалата бирелә торган түләү тәртибе**
**турындагы нигезләмәне раслау турында"гы**
**7нче карарга үзгәрешләр кертү турында**

Законнарга үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Петровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**Петровка авыл җирлеге Советы**

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендәге XXXXV сессиясенең «Петровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфа биләгән затны, пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, тиешле еллар эшләгәне өчен бер тапкыр акчалата бүләкләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы 7нче карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы "Петровка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфада булучы затка (арытаба – муниципаль вазыйфадагы зат), пенсиягә чыгуына бәйле рәвештә эштән киткәндә (закон нигезендә – яше житеп, картлык яисә инвалидлык нәтиҗәсендә эшкә сәләте югалуга бәйле рәвештә иминият пенсиясе алуга хокук бирә торган яшькә җитүгә бәйле), әгәр ул зат Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы "Пектровка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфада кимендә бер тулы срокта хезмәттә булган, муниципаль яки дәүләт вазыйфаларында гомуми эшләү стажы 15 елдан да ким булмаса, Татарстан Республикасынын 2009 елның 12 февралендә чыгарган "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында"гы №15-ЗРТ Законына туры китереп, пенсиягә өстәмә түләү хокукы булганда, аның эштән киткән көнгә кадәр биләгән вазыйфасында билгеләнгән айлык хезмәт хакының бишләтелгән күләмендә бер тапкыр түләү бирелә, шуннан соңгы һәр ел өчен өстәмә рәвештә 0,5 берәмлек күләмдә акчалата түләү өстәлә, әмма муниципаль вазыйфадагы кешенең айлык акчасының унлатылган күләменнән артыграк түгел.".

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Петровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы** **Р.Ф.Ибраһимов**